| ГЛАВА ЕРЫКЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АЛЕКСЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЗИРЕКЛЕ АВЫЛ БАШЛЫГЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**02.12.2021** с. Ерыкла **15**

**«Гражданнарның үзара салым акчаларын**
**кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча**
**Алексеевск муниципаль районының**
**Зирекле авыл җирлегенең Иске Муллино**
**авылында гражданнар җыенын билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Зирекле авыл җирлеге Уставы нигезендә

**карар бирәм:**

1. Гражданнар җыенын оештыручы итеп Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Зирекле авыл җирлеге башлыгын билгеләргә.
2. Алексеевск муниципаль районының Зирекле авыл җирлегенең Иске Муллино авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2021 елның 17 декабреннән 18 декабренә кадәр график нигезендә билгеләргә (Кушымта).
3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Зирекле авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2022 елда үзара салым кертүгә сез, 1 нче төркем инвалидлардан, көндезге уку студентларыннан, Россия Армиясе сафларына ашыгыч хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш, 500 сум күләмендә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү белән килешәсезме:
- җирлек эчендәге юлларны карап тоту;
- җирлек эчендәге юлларны ремонтлау;
- торак пунктларда урамнарны яктырту;
- су белән тәэмин итү челтәрләрен карап тоту;

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, Зирекле авыл җирлеге башкарма комитетына җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә акча җибәрергә рөхсәт итәргә.

ӘЙЕ ЮК».

4. Әлеге карарны Зирекле авыл җирлегенең рәсми сайтында, хокукый мәгълүмат порталында, шулай ук Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль

районының Зирекле авыл җирлеге Советы бинасында мәгълүмат стендында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Алексеевск муниципаль районының Зирекле авыл җирлеге башлыгы** **В.А.Данилова**

Кушымта

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының
Зирекле авыл җирлегенең Иске Муллино авылында
үзара салым кертү мәсьәләсе буенча
гражданнар җыенын этаплап уздыру
ГРАФИГЫ

| Тәр-тип саны | Үткәрү датасы | Үткәрү вакыты | Үткәрү урыны | Урамнарның исеме |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 17.12.2021 | 10 сәг. | Татарстан Республикасы, Алексеевск районы, Иске Муллино ав., Гагарин ис.ур., 33 й., авыл клубы | Пролетар ур., Көньяк-Көнбатыш ур. |
| 2 | 18.12.2021 | 14 сәг. | Татарстан Республикасы, Алексеевск районы, Иске Муллино ав., Гагарин ис.ур., 33 й., авыл клубы | Гагарин ис.ур., Кояшлы ур. |